**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «30» апреленнән № 103

**«Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфасына керешүче затлар, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 ел, 28 март, 167 нче карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфасына керүче затлар, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 ел, 28 март, 167 нче карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктның 3 абзацында «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә

алмаштырырга.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда (http:/ / pravo. tatarstan. ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдиренә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**Җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**